# И Ходаем, кыйл гыйнәят

Запись Масгуды Шамсутдиновой



И Ходаем, кыйл гыйнәят, барча эшкә Син кәфил,
Әнтә Рабби, әнтә Хәсби, әнтә нигъмәткә вәкил.
Я Ходаем, Рәхмәтеңдин безне мәхрүм кыйлма, Син,
Күңлебезнең ак күгәрчендәй теләген тыңла, Син.
Күңлебездә шулкадәр тәмле теләкләр, Раббымыз,
Фатыйма берлән тибә безнең йөрәкләр, Раббымыз.
Мәңге мәгъсүм, мәңге нурлы булса иде күңлебез,
Әкрен-әкрен, ямьле, һәйбәт үтсә иде гомребез.
И Ходаем, без фәкыйрь бәндәңне ал үз рәхмәтеңә,
Күңлемә сал гыйлем дәртен, бир гыйлем, Раббым, миңа.
Бир миңа дин вә гыйлем амбарларыңның ачкычын,
Бир миңа шул сәгадәт тауларыңның баскычын.

©